**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ УЛЬЯНОВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**УЛЬЯНОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

Центральная ул., 44 дом, Ульяновка село, 423115 тел./факс+7(84396) 2-33-16/2-33-17; email: Ul.Cmn2@tatar.ru Үзэк урамы, 44 йорты, Ульяновка авылы, 423115

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге Советы
**КАРАРЫ**

**№ 85** **31 гыйнвар 2023 ел**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 76 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 17 сентябрендәге 1015 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Ульяновка авыл җирлеге Советының 2018 елның 25 апрелендәге 76 номерлы «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Ульяновка авыл җирлеге депутатларның, үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле

үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» карарына (Ульяновка авыл җирлегенең 2018 елның 28 августындагы 89 номерлы, 2018 елның 15 ноябрендәге 93 номерлы, 2020 елның 23 октябрендәге 8 номерлы, 2022 елның 17 ноябрендәге 78 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 1 пунктындагы 3 абзацын бәян итәргә: «Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгече вазыйфаи окладының күләме 12688 сум тәшкил итә»;

1.2. 1 нче кушымтада III бүлекнең 1 пунктындагы 6 пунктчасында түбәндәгеләрне бәян итәргә: «6) айлык акчалата бүләк - вазыйфаи окладларының 18 процентыннан артмаган күләмдә»;

1.3. 7 нче кушымтаның 1 пунктын бәян итәргә: «Муниципаль хезмәткәрләргә премиядән тыш айлык акчалата бүләк түләнә. Муниципаль хезмәткәрләрне айлык акчалата бүләкләү җирле үзидарә органы җитәкчесе карары белән вазыйфаи окладның 18 процентыннан артмаган күләмдә билгеләнә»;

1.4. «3 нче кушымта «Авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен» 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.5. 1 нче кушымтада I бүлекнең 3 пунктында бәян итәргә: «Авыл җирлеге башлыгына ай саен акчалата бүләк түләнә. Күрсәтелгән затларның хезмәт өчен түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә башлыклар өчен елына айлык акчалата түләүнең 9,26 тәшкил итүче нормативтан артып китә алмый».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

ТР Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге
башлыгы, Советы рәисе С.З. Шәмсетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Ульяновка авыл җирлеге Советының
2023 елның 31 гыйнварындагы
85 номерлы карарына
1 нче кушымта

Үз вәкаләтләрен авыл җирлегендә даими нигездә гамәлгә ашыручы
авыл җирлеге башлыгының айлык акчалата бүләкләү күләме

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башлык | 17390,00 |